# КАРАР

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге составына керүче Имәнлебаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**11.11.2025ел** **№ 2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Югары Шепкә авыл җирлеге Уставы белән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. 2025 елның 11 ноябрендә «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Имәнлебаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, I төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2026 елда үзара салым кертүгә 600 сум күләмендә ризамы һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:

-Урам тренажерлары сатып алу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 169 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 113 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 98 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 15 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Имәнлебаш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. Яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Имәнлебаш торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндез белем алучы студентлардан, I төркем инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан,Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2026 елда үзара салымны 600 (алты йөз) сум күләмендә кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:

- -Урам тренажерлары сатып алу буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3.Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Имәнлебаш торак пунктының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» кабул ителгән көннән 7 көн дәвамында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Шепкә авыл җирлеге башлыгы ____________ Камалиева Л.М.